ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.11.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4391**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районының физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 маендагы 870 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында, 2023 елның 15 ноябрендәге 3574 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 07 мартындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт әзерлеге буенча өстәмә мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 127 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районының физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 маендагы 870 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» (Башкарма комитетның 2023 елның 15 ноябрендәге 3574 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне искә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1 пунктның өченче абзацында «20 000» саннарын «100 000» саннарына алмаштырырга;
2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручыга йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин